Министерство образования Республики Башкортостан
Муниципальное учреждение отдел образования Администрации
муниципального района Стерлитамакский район Республики Башкортостан
Муниципальное  общеобразовательное бюджетное учреждение
средняя общеобразовательная школа с.Талачево муниципального района
Стерлитамакский район Республики Башкортостан

# Үлмәс җыр

**(Фатих Кәрим иҗатына багышлана)**

Научный руководитель Рахматуллина Зиля Маратовна,
учитель татарского языка и литературы высшей категории

Стерлитамакский район, 2018-2019 учебный год

## Кереш

Кеше, ул кайсы җирнеке, кайсы чорныкы гына булмасын, күп кенә уртак сыйфатларга, эш гамәлләргә ия. Ул туа, үсә, эшли, сөя, сөелә, бала тәрбияли, сөенә, көенә, картая, үлә һ.б. Дөньяга ничәмә-ничә миллиард кеше килеп киткән.Хәзер күпме яши? Әмма аларның берсе дә бер-берсе белән үзара тәңгәл килми, һәрберсенең үз төс-кыяфәте, холык-фигыле, үз язмышы бар. Димәк, гомүмән, кеше юк, ә конкрет адәм баласы, конкрет шәхес бар.

Мин бу хезмәтемне Фатих Кәримнең иҗатына багышлыйм.Аның Башкортстан җирлегендә туган татар язучысы булуы да мине кызыксындырды.

Фатих Кәрим – татар шигъриятенең сәнгатьчә үсешен яңа, югары дәрәҗәгә күтәреп, гражданлык каһарманлыгы һәм шигъри батырлык күрсәтеп милләтебезнең һәм аның сүз сәнгатенең йөз аклыгы булырлык мирас калдырып һәлак булган шагыйрь. Ул дөньяда тик 36 ел гына яшәде. Шуның дүрт елы төрмәдә, дүрт елы сугышта үткәнен искә алсаң, аның гомере нинди кыска булганлыгын күрәсең.Аның һәлак булганына 70 ел тулды, әмма исеме телләрдән төшми, еллар үткән саен күңелләргә якыная бара. Бишбүләк районында  Фатих Кәрим премиясе билгеләнгән, шулай аның туган авылындагы мәктәп Фатих Кәрим исемен йөртә, Ает авылында төп урам да аның исеме белән аталган. Үз авыл халкы Фатих Кәрим турында бик горурланып сөйли.

Фатих Кәрим иҗатын өйрәнү вакытында миңа укытучым белән Биҗбүләк районы Ает авылын, аның туган йортын, туган авылын, музеен күрергә насыйп булды.Авыл халкы белән күрешү һәм аралашу да минем өчен зур сөенеч булды.

## Фатих Кәрим  хакында кыскача белешмә

Һәркемнең дә беренче тапкыр аваз салып,беренче сулышын алган туган ягы,туган  туфрагы берәү  генә, ул һәркемнең дә күңеленә газиз, ата-анасыдай якын һәм кадерле. Бик күп шагыйрьләр һәм язучылар туган ягына, аның табигатенә дан җырладылар һәм җырлыйлар.Үзенең иң мөкадәс, иң югары, иң якты уй һәм тойгыларын, теләкләрен һәм омтылышларын газиз Ватан исеме белән бәйләүчеләрнең берсе- әдәбиятыбызда җуелмас эз калдырган патриот-шагыйрь Фатих Кәрим.

Фатих Кәрим куе әрәмәләр, яшел тугайлар эченнән аккан зәңгәр тасмадай , матур Дим буена утырган Ает авылында (Бишбүләк районы) мулла вазифасын үтәүче Әхмәтвәли картның гаиләсендә унберенче – төпчек бала булып, 1909 елның 9 гыйнвары көнне дөньяга килә.

Сигез яшьтә үк әтисез калган Фатихка ятимлекнең ачы-төчесен иртә татырга туры килә. Башлангыч белемне туган авылы Аеттагы кечкенә мәктәптә ала. 1922 елда, абыйсы Габдулла Кәримовка (Ярлы Кәримгә) ияреп, Фатих Бәләбәй шәһәренә бара һәм революциядән соң ачылган педагогия техникумының әзерлек группасына укырга керә. Ике ел укыгач, ул Казанга килеп, бер ел Н.К.Крупская исемендәге балалар йортында тәрбияләнә. 1925-1929 елларда Казан җир төзү техникумды укый. Шунда укыганда ул  Кадрия Ишукова  (аның тормыш иптәше) белән таныша. Техникумда укыган вакытта Фатих иң беренче шигырьләрен кәгазь битенә төшерә башлый.   Соңрак төрле гәзит-журнал редакцияләрендә эшли, шул чагында инде ул иҗат эшенә ныклап керешә.

## II. Тыныч еллар лирикасы

Лирик шигырь яза торган шагыйрь нечкә, нәфис күңелле, кичергәннәрен башкаларга да “йоктыра” алырлык итеп әйтеп бирә белү сәләтенә ия була.Кешенең лирикада ачылган рухи дөньясы аша без ул кешене дә, аның кичерешләрен дә күз алдына китерәбез.

Фатих Кәрим – табигать кочагында үскән шагыйрь,яшьтән үк тирә-юньне күзәтүе, бай табигать белән берегеп яшәве аның поэзиясендә нык сизелә. Кеше белән табигатьне ул бербөтен итеп кабул итә.Аның беренче шигыре 1927 елда Мәскәүдә чыга торган “Кечкенә иптәшләр” журналының 2 нче санында басыла. Ул “Хәзер сезнең белән” дип атала.Әсәрдә сурәтләнгән көтүче малайга әтисе курай бүләк иткән. Малай аны ямьле җәйге урман буйларында уйната, аның кураена сандугачлар кушылып җырлый. Ата-анасыз малайга бу зур юаныч. Малай өчен авыл халкы , акча җыеп, аңа укырга мөмкинлек тудырган, ул укырга килгән. Биредә дә кулыннан яраткан кураен төшерми. Әтисе элек, курайда моңлы көйләр уйнап, тыңлаучыларны елаткан, ә малай шатлык көе уйный. Бу шигырьдә кечкенә Фатихның үз язмышын күренә. Ф.Кәримнең поэзиясе моң һәм хисләр агышыннан туа, укыган саен җыр булып күңелгә керә: “Шомырт”, “Кыңгыраулы яшел гармун”, “Идел” кебек лирик шигырьләрен укып туярлык түгел.

**“Соңгы тапкыр карыйм Иделгә”** шигырендә Идел шигъри образ итеп, Туган илнең, тыныч тормышыбызның образы итеп сурәтләнә.

Соңгы тапкыр карыйм Иделгә,
Соңгы тапкыр карыйм акканын,
Бәлки, бик тиз кире кайтмамын,
Сакланыр ул бары күңелдә.

Шигырьдә яз килеренә ышану, кыр казлары, иркен болыннар, назлы аккош моңы турында искә алулар бөтен бер пейзаж – газиз туган җир сурәтен тудыра.

## III Фронт лирикасы

Фатих Кәрим –һәр шигырь юлы белән Ватанга фидакарь хезмәт иткән җырчы һәм солдат. Аның Казан музеенда саклана торган шинеле генә түгел, кульъязмаларының соңгы битләренә кадәр пулялар белән тишкәләнеп беткән.

Юлбасарлар таптый җиребезне,
Ватан сугышына мин китәм.

Менә-балам.Син әнкәсе аның,

Балабызны тотып ант итәм.

Синең өчен, шушы балам өчен,

Нәселем өчен, Туган ил өчен,

Мылтык тотып баскан җиремнән

Бер адым да артка чигенмәм...(“Ант” 1942 ел)

Фатих Кәрим 1941 елның 30 декаберендә сугышка китә. Аның каләм көче бу елларда аеруча ныгый. Шагыйрьнең госпитальдән җибәргән хатында мондый юллар бар: “ Язам. Окопта да яздым, сугышта да яздым, монда да язам. “Совет әдәбияты” белән “Кызыл Татарстанга” күп әйберләр җибәрдем. Тик язган әйберләремдә анда ни бәя бирәсездер? Ә мин язам да язам. Кирза итекнең кунычын өстәл итеп, шыгрым тулы товарный вагон полный ходка барганда да язам. Шигырь язарга өйрәнү өчен кичергән елларның файдасы күп булды. Тик менә кәгазь юк”.

Сугыш...Дәһшәтле, явыз сугыш... Туган илемә күпме корбан, күпме явызлык, күпме күз яшьләре китерүче сугыш...